КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 17 июль г.Казань № 846

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 25 сентябрь, 853 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 25 сентябрь, 853 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 6 май, 380 нче; 2020 ел, 16 апрель, 294 нче; 2020 ел, 1 сентябрь, 768 нче; 2020 ел, 3 ноябрь, 989 нчы; 2021 ел, 21 июль, 633 нче; 2021 ел, 26 июль, 645 нче; 2021 ел, 30 октябрь, 1030 нчы; 2022 ел, 26 май, 489 нчы; 2022 ел, 20 июнь, 587 нче, 2022 ел, 14 сентябрь, 1002 нче, 2022 ел, 30 ноябрь, 1268 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының спорт әзерлеге буенча өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы дәүләт оешмалары һәм Татарстан Республикасының спорт әзерлеге дәүләт үзәкләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында»;

1 пунктның икенче һәм өченче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының спорт әзерлеге буенча өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы дәүләт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында нигезләмә;

эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләренең, Татарстан Республикасының спорт әзерлеге буенча өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы дәүләт оешмалары һәм Татарстан Республикасының спорт әзерлеге дәүләт үзәкләре җитәкчеләренең, белгечләренең

һәм хезмәткәрләренең гомумтармак вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмә;»;

2 – 4 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Әлеге карарның 1 пункты нигезендә билгеләнә торган Татарстан Республикасының спорт әзерлегенең өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы дәүләт оешмалары һәм Татарстан Республикасының спорт әзерлеге дәүләт үзәкләре хезмәткәрләренең хезмәт хакы әлеге карар нигезендә хезмәткә түләүнең яңа шартларына күчү вакытына гамәлдә булган хезмәткә түләү системасы нигезендә түләнә торган хезмәт хакыннан азрак була алмый, бу вакытта хезмәткәрләрнең вазыйфаи бурычларының күләмен саклап калу һәм аларның шул ук квалификация эшләрен башкару шарты белән башкарыла.

3. Татарстан Республикасының спорт әзерлегенең өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы дәүләт оешмалары һәм Татарстан Республикасының спорт әзерлеге дәүләт үзәкләре җитәкчеләренә Россия Федерациясенең Хезмәт кодексы нигезендә :

Татарстан Республикасының спорт әзерлегенең өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы дәүләт оешмалары һәм Татарстан Республикасының спорт әзерлеге дәүләт үзәкләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартларын билгели торган күмәк шартнамәләргә, килешүләргә, локаль норматив актларга тиешле үзгәрешләр кертүне тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасының спорт әзерлегенең өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы дәүләт оешмалары һәм Татарстан Республикасының спорт әзерлеге дәүләт үзәкләре хезмәткәрләренә әлеге карар белән билгеләнгән хезмәткә түләү системасы кертелгәнгә кадәр ике айдан да соңга калмыйча хезмәтнең җитди шартларын үзгәртү турында хәбәр итәргә.

4. Җирле үзидарә органнарына спорт әзерлегенең өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль оешмалар хезмәткәрләре өчен хезмәткә түләү шартларын 2023 елның 1 сентябреннән урнаштыру буенча шундый ук карарлар кабул итәргә тәкъдим итәргә.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлгән);

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында спорт резервын әзерләү гамәлгә ашырыла торган дәүләт физкультура спорт оешмаларында эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләренең, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлгән).

2. Бу карар 2023 елның 1 сентябреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин